Гыйбадуллина, А. Т. Матур гаилђ – миллђт горурлыгы [гаилђ къненђ багышланган  сценарий] / А. Т.  Гыйбадуллина //Ачык дђрес. – 2024. – №2. – Б. 1-4.

Һәр дәрес нәтиҗәле булсын!

Ачык дәрес

(Открытый урок)

Февраль № 2 (237)
2024

Укытучылар өчен методик ярдәмлек 12+

2024 ел - Россиядә гаилә елы - 1- 7 бит

Югары сыйныфта дәресләр - 8 - 14 бит

Югары сыйныфта чаралар - 14 - 24 бит

Башлангыч сыйныфта дәресләр - 24 - 32 бит

Башлангыч сыйныфта чаралар - 32 - 35 бит

Балалар бакчасында - 36 - 48 бит

*2024 ел—Россиядә гаилә елы*

# Матур гаилә - милләт горурлыгы

**Алсу Гыйбадуллина**
Яр Чаллы шәһәре 12 нче татар китапханәсе

**1 алып баручы.** Гаиләм - ныклы терәгем,
Гаиләм - таянычым,
Йөрәк җырым, сер сандыгым,
Һәм илһам чыганагым.

Хәерле көн, хөрмәтле әти-әниләр, кадерле укучылар! Бүген без сезнең белән Гаилә бәйрәменә җыелдык. Ел да 15 майда - табигатьнең иң гүзәл вакытында Халыкара гаилә көнен билгеләп үтәбез. Гаилә кешенең таяныр ноктасы, һәркем өчен кадерле урын. Ул кешене шәхес буларак формалаштыра, рухи һәм әхлакый тәрбия бирә, иң матур гореф-гадәтләрне сакларга һәм үстерергә ярдәм итә. Үз йортында бәхетле булган гына бәхетле. Кеше яшәешенең асылын шушы гап-гади сүзләр ача да сала. Гаилә бәйрәме дә бәхетле булуның һәм үзара аңлашып яшәүнең кыйммәтен тагын бер мәртәбә искәртү өчен тәгаенләнә. Көнозын дөнья куып арган адәм баласы гаилә ышыгында аз гына булса да ял итә, рухи көч һәм дәрман җыя.

**2 алып баручы.** Бу заманда, һәр кешегә кайтып сыеныр өчен җылы учак, тыныч почмак булу кирәк. Гаилә - ул иң ышанычлы сыеныр урыныбыз. Ни генә булмасын, кеше гаилә кочагында ял итә, рухи көч, дәрман җыя. Гаилә тормышы һәрберебез өчен очсыз - кырыйсыз хезмәт һәм сикәлтәле гомер юлы. Ашкынам гаиләмә!
Ул - аңлый күңелемне,
Ул - керә хәлемә:
Абынсаң - җитәкли,
Егылсаң - торгыза...
Еласаң - юата,
Шатлансаң - куана!
Гаилә ул - туган йорт,
Гаилә ул - Җир-Ана!
Гаилә ул - үткәнең,
Гаилә ул - киләчәк!
Гаилә ул - балалар,
Сөекле оныклар,
Киленнәр, кияүләр,
Әбиләр - бабайлар,
Алмалы бакчалар!
Гаилә ул - ут янган,
Елмайган тәрәзләр,
Төнлә дә бикләнми көтүче капкалар,
Ачкычсыз йозаклар,
Мул сыйлы табыннар,
Мамыклы мендәрләр,
Иң җылы юрганнар!
Мал тулы сарайлар!
Гаилә ул - адымнан танучы,
Йорт- җирең саклаучы - эт, мәчең,
Таң белән уяткан гайрәтле

*Хөрмәтле укытучылар! «Ачык дәрес» газетасына Россиянең барлык өлкәләрендә һәр айдан язылырга мөмкин. Язылу индекслары: Татарстан өчен Почта России (ПАП) каталогында **П2345**, оешмалар өчен **П2348**.*
*Россиядә: Почта России (ПАП) каталогында **П2345,** оешмалар өчен **П2348**.*

әтәчең,
Җыр сузган тавыклар,
Кәҗәләр, сарыклар,
Борынны кытыклар
Ак тупыл мамыклар...
Гаилә ул - бер дәүләт,
Гаилә ул - гөлләмә!
Шуннан да кадерле
Берни юк күңелгә!
Гаилә ул - пар канат,
Дәртле җыр, яшәеш!
Тормышның иң серле,
Иң матур утравы!
Гаилә ул - бәхетнең йозагы,
Мәхәббәт тозагы,
Тәрбия учагы,
Әниләр кочагы! ("Гаилә ул."
Р. Сәетгәрәева.)

**1 алып баручы.** Әйе, кешенең иң зур бәхете - аның гаиләсе. Нәрсә соң ул гаилә?

**2 алып баручы.** Бер социолог аны "җанга шифалы ял" дигән, ә икенчесе "психологик сыену урыны" дип атаган. Гомерне ничек матур һәм мәгънәле итеп үткәрергә соң? Язучы Ф. Бәйрәмова сүзләре белән әйтсәк: " Бу дөньяда адашмыйча саташмыйча, ялгыш юлларга кереп китмичә, кадерсезлекләргә төшмичә, санап кына бирелгән шушы гомерне ничек мәгънәле, файдалы, бәхетле итеп уздырырга? Иминлекнең, кадер-хөрмәтнең ачкычы кем кулында?"

**1 алып баручы.** "Агач- яфрагы, кеше баласы белән матур", - ди халык. Борынгы һәм урта гасыр әдәбиятына күз салып, Алтын Урда чоры шагыйре Котбның сүзләренә игътибар итсәк, аларның дөреслегенә инанасың. "Кеше – галәмнең олы заты, ул үзен түбәнлеккә төшерергә тиеш түгел: дөньяга килгән икән, гыйлем - һөнәр тупларга, холкын тәрбияләргә, игелекле балалар үстерергә, сөяргә һәм сөелергә бурычлы. Бары шул вакытта гына кеше, гәрчә бу дөньядан китеп туфрак булса да, буыннар хәтеренә игелекле исем белән кереп кала", - дигән ул.

**1 алып баручы.** Казан ханлыгы чоры шагыйре Өмми Камалның сүзләрендә дә гыйбрәт бар: "Дөнья ул кәрвансарай булса, ә кешеләр – шул йортта кунып чыгучы кунаклар гына".

**2 алып баручы.** Чыннан да, уйласаң, кеше гомере нинди кыска! Бу кыска вакыттан оста файдаланып, гомерне матур һәм мәгънәле итеп үткәрергә кирәк. Иминлекнең, кадер-хөрмәтнең ачкычы үзебезнең кулда.

Гаилә генә димә, ул - бер дәүләт,
Шул дәүләтләр төзи ил нигезен.
Ул дәүләттә газиз ата-ана
Төп урынны тота - йорт җилеген!
Бала гына димә, ул - киләчәк,
Күз ачып йомганчы үр менәчәк!
Бүгеннән үк уйлан үргә менгәч
Газиз балаң синең ни күрәчәк?...
Бу карт-коры диеп кул селтәмә,
Тере тарих йөри бәхетеңә!
Үткәнеңне белми - киләчәк юк,
Утырт аны гаилә тәхетенә!
Дәүләт кенә димә, үз көчеңә
Таяна бел, гаиләң хакы өчен!
Безнең туры юлдан, тырышлыктан
Туплана ул газиз Ватан көче!
Ул бит түрә димә, үз сүзең әйт,
Дәүләт булгач, сүзең булсын көчле.
Бозма аның канун, законнарын,
Бер тарафка юнәлдерик көчне!
(«Гаилә гимны» Р. Сәетгәрәева.)

**2 алып баручы.** Бүгенге гаилә бәйрәмебезгә ямь өстәп, укучыларыбыз әти – әниләргә «Парлы бию» бүләк итәләр.
(укучылар башкаруында бию)

**1 алып баручы.** Табигать бар нәрсәне парлы итеп яраткан. Агачлар, кошлар, җанварлар, башка тереклек ияләре кебек, кешеләр дә парлы яратылган. Тулы, парлы гаиләдә без үз-үзебезне ышанычлы, терәк-таянычлы итеп тоябыз. Бу тормышта бер-берең,ә кирәк булып яшәүләргә ни җитә?!

**2 алып баручы.** Әгәр ике яшь йөрәк бер-берсен таба икән, гаилә туа… Гаиләнең терәге – ир-ат, әти кеше. Әтиләр гаиләне яклаучы, гаилә намусын саклаучы, туендыручы, мал табучы, яшәү шартлары булдыручылар. Безнең татар халкында ир кеше шушы күркәм, матур сыйфатлары өчен хөрмәткә лаек булган. Ир- ат өйдә юк чакта тормыш ямьсезләнеп, төссезләнеп, туктап калган кебек. Ата хакы хаклауга карата борынгылар болай дигән: "Атаңа ни кылсаң, алдыңа шул килер".

**1 алып баручы.** Әни - ул һәркем өчен кадерле һәм изге зат. Тормышыбызга ямь бирүче, шәфкатьле, иң мәрхәмәтле газиз кешебез. Әни баласына тормыш бүләк итә, күкрәк сөте белән туендыра, сулышы белән җылыта, назы белән иркәли. Баланың иң якын киңәшчесе дә, хәленә керүче дә, кайгысын һәм шатлыгын да үз йөрәге аша үткәрүче кеше - ана. Пәйгамбәребез ана хакы турында мондый хәдис әйткән: «Әүвәл анаң, аннан соң анаң, аннан соң да анаң, аннан соң гына атаң»! Ананың йөрәге үлгәнче, балам диеп тибә, гомере буе баласы өчен яши. "Җәннәт аналарның аяк астында," – диелә хәдистә. Коръән буенча, хатын-кызның, ананың хакы олы. Аналар үпкәсе күп булса да, язгы кар суы кебек тиз эрер, диләр.

**2 алып баручы.** Әти-әни гаиләнең томкасы булса, балалар - гаиләнең көзгесе.

“Бала - гаиләнең көзгесе: су тамчыларында кояш чагылган кебек, балаларда да ана һәм атаның әхлакый чисталыгы чагыла”,- дип язган В.А.Сухомлинский. Әгәр дә тотка купмасын, көзге ватылмасын дисәң, бер - береңне саклап, рәнҗетмичә хөрмәтләп яшәргә кирәк. Әни-әти булганда һәркем бәхетле. Дөньяның бернинди байлыгы да, бер кеше дә, зиннәтлелек тә аларны алмаштыра алмый!

**1 алып баручы.** Гаилә ул - җылы учак. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык шулкадәр көчле була. Гомер юлыннан бер-береңне аңлап, ярдәм итеп, кирәк вакытта юл куеп яшәүче гаиләләр бик күпләребездә соклану уята. Чөнки ике гаиләдән кушылган кешеләргә бер-берләренең гадәтләренә өйрәнеп, бер-берләрен кабул итеп, үз гаиләләрендә үз тәртипләрен булдырып яшәүләре зур түземлелек таләп итә. Шундый түземлеләр генә гаилә дигән дәүләтне таркатмый яши ала да.

**2 алып баручы.** «Тату гаилә - бәхетле гаилә», - ди халкыбыз. Нәрсә ул бәхет?

**1 алып баручы.** Бу сорауга җавап итеп Л. Шиһабиеваның «Хыянәт» хикәясеннәннән алынган өзекне укып китик:

- Әни, син бәхетнең ни икәнен беләсеңме?

Беләм, балам. Ул – әти-әниең янында булу, авырмыйча, борчылмыйча яшәү. Ә синең өчен тырышып уку, “5”ләләр алу....

- Ә синең өчен?

-Бу сорауларны каян җыеп бетерәсең син? Минем өчен дә шул инде: дәү әти, дәү әниең исән-сау булса, әтиең янымда булса, сез авырмасагыз...

- Әти булмаса... Әти булмаса син куркыр идеңме, әни?! Әти өйгә кайтмаса, аны каян эзләп карар идең...

- Ай, балам, авызыңнан җил алсын! Ник кирәкмәгән нәрсәләр сөйлисең син. Бар “тьфу“ диген, төкер. Әтиеңне аптыратмыйча, аны бер пәп итмичә йокларга да ята алмыйсыз бит... Кирәкмәгән нәрсәләр сөйләп торасың.

Ләйсән кечкенә кызы Таңсылу белән булган шушы сөйләшүдән соң, үзе дә уйланып, агачка шакып куйды. Илдар янында булмауны башына да китерә алмый ул. Ул кайтмыйча йокларга да ятканы юк бит. Көчле ир иңнәре артында яшәргә ияләшкән. Ире акыллы һәм тырыш булганга күрә, ышанып 3 бала тапкан да инде. Үзең генә 3 баланы кеше итә торган замана түгел. Усаллардан да сакларга, гаиләдәге яратуны да киметмәскә кирәк.

**2 алып баручы.** Укучылар, ә сез ничек уйлыйсыз? Нәрсә ул бәхет? (Укучыларга сүз бирелә)

**1 алып баручы.** Бәхетле булу өчен гаиләдә аңлашып, хөрмәт итеп, тату яшәргә кирәк. Өебездә бер-берсен яраткан, бер-берсе турында кайгыртучанлык күрсәткән кешеләр яши. Ничек инде алар бәхетле булмасын да, киләчәккә омтылмасын! «Гаилә бәхете - ил бәхете», - ди халык. Ә ул бәхетне әти белән әни тудыра. Җир йөзендә гомер юлын матур итеп бергә атлаучы, күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшәүче, матур киләчәккә омтылучы гаиләләр күп булуын теләп, Алинә Шәрифуллина башкаруында «Әткәй - шикәр, әнкәй - бал» җырын тыңлап узыйк. (җыр башкарыла)

**2 алып баручы.** Һәр гаиләнең үз традицияләре, милли бәйрәмнәре һәм гореф - гадәтләре, буыннан - буынга тапшырылып килүче гаилә ядкарьләре бар. Аларны һәркем үзенчә үткәрә. Бәби туйлары, баланың беренче мәртәбә “әннә”, “әттә” дип эндәшүе, балалар бакчасына китүе, соңыннан мәктәпкә йөри башлавы һәр гаилә өчен бетмәс-төкәлмәс шатлык китерә. Туган көннәр билгеләп үтү дә матур бер традициягә әверелде. Гаиләнең ныклыгы, татулыгы бик күп нәрсәләргә бәйле. Әйдәгез, шулар турында сөйләшеп алабыз. (Укучыларга сүз бирелә)

**1 алып баручы.** Бер-береңә күлмәк итеп,
Кирәк чакта терәк итеп,
Аллаһ безне парлап яралткан.
Калебеңә сихәт бирер,
Үзең кебек якын күрер –
Берәү генә бит ул җан тарткан.
Бер-береңә хәләл итеп,
Балдан татлы, тәмле итеп,
Аллаһ безне шулай яралткан.
Ике ятны берләштерә,
Сөйләштерә, киңәштерә, -
Гаилә ул - учак, җан тарткан.
Бер-береңнән сүрелмәсен,
Иман нуры һич сүнмәсен,
Гаиләләр ныклы булсыннар.
Таза, матур еллар килеп,
Тигез канат белән яшәп,
Кыз-малайлар ешрак тусыннар. («Гаилә учагы сүнмәсен» Р.Сәрвәрова)

**2 алып баручы.** Чыннан да, гаилә тормышы – исәпсез-хисапсыз хезмәт, сикәлтәле гомер юлы. Шул юллардан гомер буе бер-берсен аңлап, бер-берсенә ярдәм итеп, бер-берсенә юл куеп яшәүче гаиләләр – һәр кешедә соклану уята. Һәр гаиләгә

исән-сау булып, сәламәтлек белән яшәүләре насыйп булсын. Йортларыбызда тынычлык, татулык, үзара аңлашу булсын.

**1 алып баручы**. Шатлык булсын һәрбер өйдә,
Борчу ишек какмасын!
Бердәмлектә, бергәлектә
Тормышлар гөрләп барсын!
Котлыйм әле, котлыйм сезне
Гаилә көне белән!
Гаиләләр тигез булсын,
Яшәгез һәрчак бердәм!

Хөрмәтле кунаклар! Бу бәйрәмдәге якты теләкләребез тормышка ашсын! Балаларыгыз сезгә карата рәхим-шәфкатьле булсыннар иде. Әгәр бүген сезнең йөзләрегез балкый һәм кәефегез яхшыра икән, иртәгә эшегездә җиңелрәк булыр. Бу залда кабынган елмаю йортларыгызда дәвам итсен. Гел шулай якты йөзле, тәмле сүзле булып калыгыз, тыныч, мул тормышта яшәгез. Һәр гаиләгә бәхет һәм иминлек телибез.

**2 алып баручы.** Бүгенге кичәбезне Айдар Минһаҗев сүзләренә язылган «Нинди рәхәт бит ул безнең өебез» җыры белән тәмамлыйбыз. (җыр башкарыла)